**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4359**
**23.08.2019**

Башкарма комитетның капиталь төзелеш
объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә
рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентын
раслау турында 2013 елның 31 июлендәге
4534 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелешкә рөхсәт һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә җибәрү турында» 2017 елның 4 июлендәге 788 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә рөхсәт һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә җибәрү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 31 июлендәге 4534 нче карарына (Башкарма комитетның 2015 елның 31 декабрендәге 7629 нчы, 2016 елның 28 июнендәге 3311 нче, 2017 елның 11 сентябрендәге 5325 нче, 2018 елның 12 июлендәге 3906 нчы, 2019 елның 27 июнендәге 3256 нчы карарлары редакциясендә), 2.5 пунктның 7 пунктчасын түбәндәгечә бәян итеп, түбәндәге редакциядә үзгәрешләр кертергә:

7) инженерлык тикшерүләре нәтиҗәләре һәм проект документларында булган түбәндәге материаллар:

- аңлатмалы язу яки аның скан-күчермәсе (электрон форманы тутырганда);

- җир участогының шәһәр төзелеше планында җир участогы күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган планлаштыру оештыру схемасы, ә проект документлары линия объектларына карата әзерләнгән очракта, территорияне планлаштыру проекты (линия объектын төзүгә, реконструкцияләүгә территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү кирәк булмаган очрактан кала) нигезендә башкарылган полоса проекты яки аның скан-күчермәсе (электрон форманы тутырганда);

- архитектура һәм конструктив карарлар булган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (проект документлары сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнеш объектларына, торак фонды объектларына карата әзерләнгән очракта) яки аның скан-күчермәсе (электрон форманы тутырганда);

- капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, капиталь төзелеш объектларын сүтү кирәк булган очракта, аларның өлешләрен, башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын кертеп) яки аның скан-күчермәләре (электрон форманы тутырганда).

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә.
Абдуллин